**СОВЕТ МЕМДЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422728, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Мемдель, ул. Кооперативная, 30

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМДӘЛ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мәмдәл авылы, Кооператив урамы, 30

Тел./факс 8(84365) 60-2-37, e-mail: Memdel.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24 августа 2020 г.** **№175**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге җирле үзидарә органының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2009 елның 12 ноябрендәге 154 номерлы карары (2009 елның 13 декабрендәге 159 номерлы редакциясендә) белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә, Мәмдәл авыл җирлеге Уставына таянып, Мәмдәл авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирләүгә тарифлар билгеләү һәм җирләү эше өлкәсендә җирле үзидарә вәкаләтле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга;
2. Әлеге карарны карау өчен Биектау муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә (Сафиуллин Фәрит Габделхак улы) Биектау муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә артмаган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзү буенча як булырга;
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сафиуллин